ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Тел./факс: (85556) 2-57-52, e-mail: gulnaz.nabieva@tatar.ru, http://muslumovo.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

__24.01.2020 г.______ Мөслим № 39

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның туклануын оештыру турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 23 августындагы 456 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

2004 елның 8 декабрендәге «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» 63-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы һәм «2020 елга айлык акчалата һәм башка төр түләүләр турында» 2009 елның 28 августындагы 724 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары нигезендә, билгеләнгән айлык акчалата түләүләрне һәм түләүләрнең башка төрләрен индексацияләү максатларында, Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тукландыруны оештыру турында» 2019 елның 23 августындагы 456 номерлы карарының 1.1 пунктына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә: «Мөслим муниципаль районының урта гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучыларны көненә ике тапкыр кайнар ризык белән, башлангыч һәм төп гомуми белем бирү мәктәпләрен кайнар төшке аш белән тукландыруны 7 сум 70 тиен (җиде сум җитмеш тиен) субсидия һәм һәр уку көненә ата – аналар түләвеннән оештырырга.
2. 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә: Күп балалы һәм аз керемле гаиләләрдән булган укучылар өчен 7 сум 70 тиен (җиде сум 70 тиен) сумга түләүсез кайнар иртәнге ашлар оештырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольда тотуны «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Мәгариф идарәсе» МКУ начальнигы Р.Т.Демидовка йөкләргә.

.

**Башкарма комитет җитәкчесе**
**вазыйфаларын башкаручы** **Ильясов Р.А.**